**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 9 октябрендәге 4241 номерлы карары**

**Монтажлау һәм сүтү эшләре алып бару**
**чорында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм**
**аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турында**

Монтажлау һәм сүтү эшләре алып бару максатыннан, шулай ук 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. 2024 елның 12 октябрендә 00.00 сәгатьтән алып 2024 елның 30 октябрендә 23.59 сәгатькә кадәр К.Маркс урамыннан алып Большая Красная урамына кадәр участокта транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне билгеләргә;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. вакытлы юл билгеләрен урнаштыру схемасын төзергә һәм транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү чорында вакытлы юл билгеләрен кую, гамәлдәге юл билгеләрен каплау буенча чаралар оештырырга;

1.2.2. Интернет челтәрендә «Татарстан Республикасының рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының рәсми

сайтында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турында мәгълүматны урнаштырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәлахетдинов) Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе (А.И.Салихов) белән берлектә йөк техникасы яисә махсус блоклар белән юлларны ябу эшен оештырырга;

1.4. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участогында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) күрсәтелгән урам-юл челтәре участогында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**